Батырша илендә. - Текст : турыдан-туры // Мәдәни җомга. – 2022. – № 26 (8 июль). – Б. 6.



# Батырша илендә



**Быел мңлли каһарманыбыз Батырша - Габдулла Галиевнның тууына - 305, вафатына 260 ел тула. Идел Болгарстанында ислам дине кабул итүнең 1100 ел лыгын билгеләп үткәндә, шәһри Болгарда да Батырша хәзрәтнең исеме зурлар искә алынды, рухына дощ кылынды. Бу эшләрнең башлап йөрүчесе Фәүзия Бәйрәмова булды. Моңа кадәр дә ул аның турында «Батырша җитәкчелегендә милли-азатлык көрәшер (2005), «Баһадиршаһ» (2006) һәм «Батырша явы» (2012) китапларын язып бастырган иде инде.**



22-25 июнь көннәрендә Ф.Бәйрәмова таган Батырша хәзрәтнең туган ягы - Башкортстанның Иске Балтач районында булып кайтты. Чараны оештыруда аңа Иске Балтач үзәгендә Батырша музеен төзеткән һәм аның директоры булып эшләүче, милли каһарманның нәсел дәвамчысы, Балтачтагы Батырша мәчетенең имам-хатыйбы, бөек Батырща явы һәм бу төбәктәге татар авыллары турында 7 китап язган Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров ярдәм итте.

Очрашулар Батыршаның туган авылы - Югары Карыш мәчетендә башланды, соңыннан Иске Балтачтагы Җәмигъ мәчетендә дәвам итте. Язучы халыкка күренекле яу тарихын сөйләде, бу төбәктә ислам диненең сакланып калуында Батырша хәзрәтнең тоткан урыны гаять зур булуын аңлатты. Мең ел буе дәүләт тоткан татар халкының хәтта дәүләтсез калганда да иманны бирмәүләрендә аерым шәхесләрнең, бигрәк тә Батырша кебек дин әһелләренең, милли зыялыларның роле зур булуын әйтте. «Милләт алдында көчләп чукындыру афәте торганда да Батырша хәзрәт кебек каһарманнар, үз гомерләрен корбан итеп, динне саклап калган. Ислам диненең 1100 еллыгын билгеләп үткәндә дә без аларга бурычлы». Ф.Бәйрәмова татар халкының дин һәм ирек өчен гасырларга сузылган тиңсез көрәшен тарихи мисаллар белән сөйләде, соңыннан мәчеткә Батырша турындагы китапларын бүләк итте.

Очрашуларда авыл мөселманнары, Иске Балтач авылының Үзәк мәчете имам-хатыйбы Филүс Камалтдинов, Югары Карыш имамы Фәнәвил Габбасов та катнашты. Алар киләсе елга авылның 330 еллыгы булуың, шул уңайдан Югары Карышка Батырша хәзрәтнең нигезенә истәлек стеласы кую мәсьәләсен күтәрде, аны туристлар маршрутына кертергә теләкләре булуын җиткерде.

Аллага шөкер, Югары Карышта урта мәктәп Батырша исемен йөртә. Тик менә Батырша хәзрәтнең нигез урыны ташландык, анда билдән үлән үсә. Батырша хәзрәтнең мәчете һәм мәдрәсәсе булган урында да бушлык. Ходайның рәхмәте белән мәдрәсәдән калган данлыклы китапханә бүген аның нәсел дәвамчысы Рәфис хәзрәттә саклана, ул борынгы китапларны Балтач музеенда күрергә мөмкин.

Янәшәдә генә Чурталыкүл. Бу - атаклы мишәр морзалары Янышевларның туган авылы, бу нәселдән чыккан биш ир туган төбәктәге тагын биш татар авылына нигез салган. Чуртанлыкүл элек мәчетле булган, тик бу авыл озак еллар мәчетсез яши. Рәфис хәзрәтнең зур тырышлыгы белән генә, элеккеге башлангыч мәктәп бинасы мәчет итеп үзгәртелә, бер бүлмәсендә авыл музеен ачалар. Җомга намазларын Иске Балтачтан килеп Йосып хәзрәт Исмаев укыта.

Район үзәге Иске Балтач Башкортстанның төньяк-көнбатышында, Пермь крае чигендә урнашкан, ул нигездә татар-мишәрләрдән тора, алар бирегә Казан ханлыгы, җимерелгәч, чукындырудан качып килә, монда Алтын Урда чорында яшәп яткан нугай татарлары янына сыена. Шуларның бер өлеше, Батырша хәзрәт кебек, динен-милләтен яклап, ХУШ гасыр урталарында көчләп чукындыруларга каршы яуга күтәрелә, икенче өлеше, Яныш старшиналар кебек, патша хакимияте белән бергә аларны бастыра. Татарның зурлыгы да, хурлыгы да янәшә йөри. Элек шулай булган, ни кызганыч, хәзер дә шулай...

Ф.Бәйрәмова милләтебезнең шушы бөек һәм фаҗигале язмышын сөйләде, чукындыруга каршы күтәрелгән Батырша явының җинелү сәбәпләрен аңлатты. Батыршаны үзебезнең мишәр-башкорт старшиналары тотып бирә, аны коткычы, дип, Петербургта хөкем итеп, телен, борынын кисеп алалар, маңгаена «вор» дип утлы тамга кыздырып сугалар һәм гомерлеккә Шлиссельбург кальгасына ябалар. Шунда дүрт елдан артык газап чигеп, үзен саклаган сакчыларның дүртесен балта белән бәреп үтергәч, Батырша хәзрәт үзе дә йөрәге ярылудан вафат була... Хатынын һәм кызларын чукындырып, монастырьга ябалар, сабый улы Уфадан Мәскәүгә озатканда, юлда катып үлә. Ислам аның бөтен гаиләсе корбан була, әмма милләте исән кала. Батырша күтәрелешеннән һәм Пугачев яуларыннан соң куркуга калган Екатерина II дин иреге турында фәрман чыгарырга мәҗбүр була. Шушы күтәрелешләр сәбәпле, башкортларга җир хокукы бирелә, мөселман татарлар чукынган татарлар өчен налог түләми башлый, керәшеннәр өчен рекрутка солдат бирми. Шул чорда Диния нәзарәте төзелә, мәчетләр салына башлый.

Әлбәттә, патшалар алмашыну белән, мөселманнарга караш тагын үзгәрә, көчләп чукындырулар шаукымы 19 гасыр буе дәвам итә, чиркәү кенәгәләренә элек керәшен дип язылган татарларның нәселе бер гасыр буе яңадан исламга кайту өчен көрәшә. Бу хәлләр Ф.Бәйрәмованың «Гөләйза» романында да ныклап тасвирланган...

Батырша мәчете белән Батырша музее янәшә тора, аның белән музей директоры Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров үзе таныштырды. Монда Ризаэддин Фәхредциннән башлап, Габделбари Баттал-Таймас, Сәлам Алишев, Җәмит Рәхимов, Фәүзия Бәйрәмова, Мәсгуд Гайнетдинов, Фәйзелхак Ислаев, Вахит Имамов, башкорт язучыларының һәм галимнәренең дә Батырша турында хезмәтләре урын алган. Әмма бирелә иң кыйммәтле ядкәр - Батырша китапханәсе. Ул 80 томнан тора, кайбер кульъязма китаплар 500-700 битле. Монда Батырша хәзрәт үлгәч басылып чыккан китаплар да бар, алар аның мәдрәсәсендә тупланган. Мәрҗани институтыннан Казан галимнәре килеп, бу китапларның өлешчә тасвирламасын ясаган, әмма күпчелек кульъязма китаплар һаман өйрәнелмәгән. Шулай ук Уфадан башкорт галимнәре дә килеп, бу китапханәне өйрәнгән, әмма аларның нәтиҗәләре билгеле түгел. Югыйсә, тулы бер фәнни институт еллар буе өйрәнерлек мирас! Шунысын да әйтергә кирәк - Батырша китапханәсе Р.Шәйхәйдаровның шәхси милке, ул аны музейга биреп кенә торган. Дәүләт бу бинага хуҗа булса да, Батырша китапларына хуҗа түгел, бәлки, яхшыгадыр...

«Батыршаның халыкка мөрәҗәгать итеп язган өндәмәсе һәм кулга алынгач, патшабикәгә язган гарызнамәсе бүген Мәскәү-Петербург архивларында саклана һәм фәнни әйләнешкә кертелгән. Шулар буенча XVIII гасырдагы милләт тормышын да, татар язмышын да белергә була, ә ул тоташ фаҗигадән тора. Батырша - шуларны язып калдыруы белән дә тарихи каһарман һәм милләт атасы! Батырша хәзрәт - милләтнең азатлык символы ул!» - диде Ф.Бәйрәмова, музей белән тагын бер талкыр танышкач.

Әйе, Батырша хәзрәткә, аның хезмәтләренә игътибар җитәрлек түгел. Бары тик Уфада, Әлмәттә һәм Иске Балтачта гына аның исемендә урамнар бар, ә Казанда урын табылмаган (?). Батырша тарихын һәм мирасын санаулы кешеләр генә өйрәнә, аның буенча фәнни эшләр юк диярлек. Моның төп сәбәбе - Батырша хәзрәтнең, үз халкын яклап, империянең татарларны көчләп чукындыру сәясәтенә каршы чыгуы. «Аны шуның өчен кичермиләр, үзен күтәрмиләр, исемен күрсәтмиләр, - диде Ф.Бәйрәмова. - 2017 елның 12 апрелендә, Петербургта уздырылган «Фәезханов укулары» кысаларында Батыршаның тууына 300 ел тулу билгеләп үтелә. Анда тарихчы Фәйзелхак Ислаев «Батырша һәлак булган Шлиссельбург крепосте диварына истәлек тактасы куярга кирәк», дип тәкъдим ясый, әмма бу русларда ризасызлык уята. Рус православие чиркәвенә караган «Всемирный русекий народный собор» дип аталган оешма вәкилләре моңа каршы чыгып, Батырша хәзрәтне «Известный антироссийский националист и религиозный фанатик», дип атый. Татарның татар булып, үз динендә калырга теләве шулай тамгалана. Хәер, әгәр Идел-Урал мөстәкыйль алган булса, Батырша хәзрәт аның түрендә булыр иде, чөнки ул - милләтнең Азатлык билгесе!»

«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге.

